...ШЕГЕЗ!



1939 НЧЫ ЕЛНЫҢ 1940 НЧЫ ЕЛГА ВАСИЯТЕ

Иптәш 1940 нчы ел!

Мин инде соңгы минутларымны үткәрәм. Алда язганнарга өстәп, сиңа тагын берничә мәсьәлә турында язып калдырам:

1. Мин татар культурасының үсеше өчен гаять әһәмиятле булган зур тарихи эшне башлап калдырам. Татар язуын рус графикасы нигезендәге яңа алфавитка күчерү мәсьәләсен принципиаль яктан чиштем һәм практик яктан башлангыч мәктәпнең 1—2 классларын, зурлар мәктәпләрен яңа алфавитка күчердем. Алар хәзер матур гына эшләп баралар. Син инде бу эшне төгәллә. Башлангыч мәктәпнең калган классларын, урта һәм урта җип татар мәктәпләренең барлыгын күчереп бетер.

2. Сиңа тагын бер эш: Наркомпрос белән без яңа алфавит буенча орфография сүзлеге төзи башлаган идек. Менә шул сүзлек әле тәмам булганы юк. Мине шул бик борчый. Халык аны бик көтә бит! Син шуны ашыктыр әле. Нарком Контюков иптәш алдында чык куй.

3. Сиңа тагын бер сүз: Миндә яңа алфавитта басылган дәреслекләрдә орфографик яктан төрлечәрәк киткән сүзләр булгалады. Яңа эш булганлыктан һәм бик ашыгыч эшләнгәнлектән, мин төзүчеләрне артык кыса алмадым. Син Корбангали һәм Фазлулла агайларны ныгырак тот инде. Алар үзара аңлашыбырак эшләсеннәр.

4. Тагын бер киңәш: Син яңа алфавитта дәреслекләр хәзерләтү белән бергә массага укыр өчен матур әдәбият әсәрләре бастыруны да онытма. Бу турыда Тенчурин иптәш белән сөйләш һәм аннан моны тиз эшләүне сора.

5. Тагын бер нәрсә бар: татар язуын яңа алфавитка күчерү уңае белән вывескалардагы татарча язуларны да яңа алфавитка күчерә башлаячаклар. Орфографиясен бозып язмасыннар. Шуны күзәтеп барырга иде. Кем күзәтер икән?

Я, ярый. Минем вактым бетте, 12 суга! Сау бул, яхшы эшлә!..

Уңышлар теләп 1939 нчы ел.

⁂

39 нчы елның 40 нчы елга карата биргән йөкләмәләрен мин үзем дә йөкләмә итеп аңлыйм һәм 1940 нчы ел эчендә шул эшләрне үтәүдә актив катнашырга сүз бирәм.

М. Фазлулла.
Профессор.

ӘЙ, ЯҢА ЕЛ!..

Әй, Яңа ел, мин беләмен
Яңа бәхет безгә киләсең;
Мин беләмен юлбашчының
Илгә яңа сөенеч бирәсең.

Теләгем бар Яңа елга,
Теләгем бар кешелек исменнән...
Мин кычкырам моны аңа
Шат һәм тыныч Совет иленнән:

— Аренадан китсен байлар!
Бетсен сугыш! Бетсен палачлар!
Ирек өчен коралланып,
Берләшсеннәр коллар һәм ачлар!

Әнә кара Токиога,
Кара Лондон, Париж ягына,
Ак финнәргә—
Әй, Яңа ел,
Карә шашкан этләр явына.

Авызын ачып сугыш тора,
Кабып йотам диеп барсын да...
Күпме халык һәлак була,
Күр син, бомба, ядрә астында.

Шатлык китерәм дип
Алсуланып ата көн дә таң...
Ләкин әче хәсрәт сөйләп
Диңгез өсләрендә ага кан.
Горур йөргән зур кораблар
Чәлпәрәмә килеп баталар,
Биек очкан самолетлар
Йомычкадай
Җирдә яталар.

Кеше эшли, иҗад итә...
Ә шул иҗад утка тотыла;
Яшәр өчен туган кешеләр
Сугыш тарафыннан йотыла.
Әй, Яңа ел, яхшы тыңла
Бу теләгем кешелек исменнән...
Мин кычкырам аны сиңа
Шат һәм тыныч Совет иленнән:
— Трибунадан төшсен байлар!
Бетсен сугыш! Бетсен палачлар!
Ирек өчен коралланып,
Берләшсеннәр коллар һәм ачлар!

Г. Кутуй.

ГҮЗӘЛ ЖИҢҮЛӘР ЕЛЫ

1939 нчы ел минем үзем өчен аеруча зур шатлыклар китергән ел булды: миңа хөкүмәт тарафыннан Татарстан республикасының халык артисты дигән мактаулы исем бирелде. Бу елда мине Казан Шәһәр Советына депутат итеп сайладылар Барыннан да бигрәк, шушы елда мин бөек коммунистлар партиясе сафларына кабул ителдем. Хәзер данлыклы партиябезнең гүзәл тарихын өйрәнәм һәм бөтен коллективыбыз белән Казан сәхнәсендә бөек даһи Ленин образын күрсәтүгә зур энтузиазм белән хәзерләнәбез.

Д. Р. Любин.
Татарстанның халык артисты, Казан Шәһәр Советы депутаты.

МИНЕМ ТЕЛӘГЕМ

1939 нчы ел—орденлы Татарстанның театр һәм сәнгатенә зур гына уңышлар бирде. Татар Дәүләт опера театрының ачылуы, Татарстан хөкүмәте тарафыннан театрларның күп кенә алдынгы работникларына мактаулы исемнәр бирелү, болар—зур тарихи фактлар. Бу фактлар—безнең чәчәк аткан бөек илебездә сәнгатнең туктаусыз үсә баруын, сәнгаткә һәм сәнгат работникларына партиябез, хөкүмәтебез һәм халкыбыз тарафыннан зур бәя бирелүен ачык күрсәтәләр.

1940 нчы елга кергән вакытта мин үземнең иң беренче теләгем итеп—ирешкән уңышларыбызны ныгыту нигезендә, театрыбызның яңа зур уңышлары өчен туктаусыз көрәш алып баруны, кадрлар тәрбияләүне куям. Театрда эшләп килүче кадрларга тиешле эш һәм тормыш шартлары тудыру белән бергә, аларның аң-белемнәрен арттыру, квалификацияләрен күтәрү өчен киң күләмдә эш алып бару—1940 нчы елның иң алдынгы бурычларыннан берсе. Шуның белән бергә, театр өчен яңа кадрлар җитештерү мәсьәләсе кискен рәвештә хәл ителергә тиеш.

Репертуар — театрның йөрәге һәм йөзе. Тамашачыларны тәрбияләү ягыннан да, театрның иҗад көчләрен үстерү ягыннан да, репертуар нигез урынны тота. Партиябезнең XVIII нче съезды кешеләрнең аңындагы капиталистик калдыкларны бетерү бурычын куйды. Бу юлда нык эш алып бару совет театрының һәм совет драматургиясенең намус бурычы. Ләкин безнең оригинал әсәрләребез эчтәлекләре белән канәгатләнерлек булсалар да, художество эшләнешләре ягыннан шактый түбән торалар әле. Шулай ук тематика ягыннан алганда да бүгенге тормыш аз чагыла. Бүгенге көннең җанлы кешеләре, бөтен нечкәлекләре белән бирелгән яңа кеше, яңа семья, үз халкы өчен нинди генә батырлыклар эшләргә дә хәзер торган совет яшьләре, стахановчылар, батыр очучылар, данлыклы Кызыл Армия һәм башка бик күп темалар безнең сәхнәдә тулы художество белән гәүдәләндерелгәннәре юк әле.

Минем теләк: авторлар бүгенге темага тирән эчтәлекле, художество ягыннан яхшы сыйфатлы, тамашачыларны канәгатьләндерерлек, артистларга иҗад итәрлек әсәрләр язсыннар иде.

Мөмкин булса, минем өчен, Ленин—Сталин эшенә чын күңелдән бирелгән совет семьясендә ата ролен язсалар зур рәхмәтләр әйтер идем. *Зәйни Солтанов.*

Татарстанның халык артисты.

АЛДА ТОРГАН ЭШЛӘР

Мин, тиңдәше булмаган 1939 нчы елгы уңышларны дулкынланып искә алуым белән бергә, 1940 нчы елның тагын да зур уңышлар алып киләчәген шатланып көтәм. Бөек коммунистлар партиясе җитәкчелегендә, СССР да ирешеләчәк уңышлар белән бер рәттән, орденлы Татарстанда түбәндәге эшләрнең тәмамлануын теләр идем:

— Дәүләт Опера театры бинасының эшләнеп тәмамлануын һәм 1940—41 нче ел театр сезонының яңа бинада башлануын.

— Орденлы драматорг Тажи иптәш Гыйззәтнең эшчеләр тормышыннан алынган пьесасын сәхнәдә күрүне, Шәриф абзый Камалның „Матур туганда“ романының дәвамын тизрәк укуны, шагыйрьләребезнең тирән магнәле шигырьләр бирүләрен телим.

Мин үзем 1940 нчы елның сентябренә югары мәктәпләрдә укыту өчен татар әдәбияты буенча (XIX — XX нче йөз) дәреслек—христоматия эшләп бирергә уйлыйм. *М. Гайнуллин.*

Казан Педагогия институтының гыйлми эшчесе

80 нче номерлы урта мәктәптә яңа ел елкасы. РӘСЕМДӘ: алгы планда—4 нче „Б“ классы укучысы Рәдифә Шаһвәлиева һәм 4 нче „Д“ классы укучысы Рәсмия Хәкимова.

И. Ғалиев фотосы.

ЯҢА ПОЭМАЛАР, РОМАННАР, ДРАМАЛАР

Минем 1940 нчы елда әдәбият-сәнгат өлкәсендә киң полотнодагы поэмалар, калын романнар, тирән тойгылы драмалар күрәсем килә. Ул әсәрләрдә хезмәт иясенең көрәш тарихында булган халык батырларын, бүгенге геройларын художество образлары югарылыгында бирелүен күрәсем килә.

Театр, музыка өлкәсендә хроник җылылыкчылыктан чыгып, хәзерге тамашачының сорауларына җавап бирерлек, акылына аң, йөрәгенә азык булырлык чын сәнгат җимешләрен күрәсе килә.

1939 нчы ел миңа „Кыю кызлар“ исемле әсәремне тудырырга мөмкинлек биргән булса, 1940 нчы елда халыкның көрәш тарихыннан алынып языла торган „Кыңгырау“ (Ялкын) әсәремне язып бетерергә, бүгенге батырларны җанландырган киң колачтагы „Таймас“ исемле әсәремне тәмам итәргә мөмкинлек бирәчәк. *Таҗи Гыйззәт.*

Орденлы драматург, атказанган сәнгат эшлеклесе.

БӨЕК КЕШЕЛӘР БЮСТЛАРЫ

Календарьның соңгы бите ертып алынды. Бу көндә, бу сәгатьләрдә җир шарындагы кешеләр гореф-гадәт буенча бер-берләренә бәхет телиләр. Бәхет! Нинди матур, тулы авазлы сүз ул.

Чит илләрдәге миллионнарча хезмәт ияләре өчен ул, бәхет—хиял гына. Безгә бәхет—ул, чынбарлык.

Бу көн, үткән елга йомгак ясау өчен, ирексездән артка борылып карарга мәҗбүр итә. Һәм ул бушка гына үтмәде дип канәгатьләнү белән әйтәм:

Мин Бөек Лениннең һәм Сталинның монументаль бюстларын, француз халкының бөек язучылары Ромен Роллан һәм Анри Барбюс бюстларын, татар әдәбияты классигы Г. Камал бюстын, заманыбызның бөек язучысы Максим Горький фигурасын эшләп бетердем. Менә үткән елның кыскача күрсәткече.

Яңа елга мин татар халык шагыйре Габдулла Тукай бюстын ясау белән керәм.

Скульптор *Садри Ахун.*

ЗУР КАЗАНЫШЛАР ЕЛЫ

Миңа әле 21 яшь кенә. Тимер юл транспортында күптән түгел генә эшлим. Шулай да, 1939 нчы ел зур казанышлар елы булып, хәтеремдә озак сакланырлык истәлекләр калдырды.

Мин бу ел 4 класс күләмендә башлангыч белем алдым. Ленин—Сталин комсомолы сафына кердем. Сторожихалыктан Казан станциясенең техник конторщигы итеп күтәрелдем. Намуслы хезмәтем өчен ике тапкыр бүләкләндем. Ниһаять, бөтен халык тантанасы—24 нче декабрь көнендә Казан шәһәр Советына депутат итеп сайландым, югары исемгә ия булдым.

Мондый үсеш, мондый ихтирам бары тик бездә, Советлар илендә генә булуы мөмкин. Бу тирән кайгыртучанлыкны мин алда да үрнәк хезмәтем белән акларммын. Миндә 7 еллык мәктәп күләмендә гомуми белем алу, станция дежурные булуга ирешү, тимер юл транспорты кебек катлаулы тармакта тагын да яхшырак эшләү теләге гаять зур. Бу теләгемнең тормышка ашырылуына нык ышанам. Чөнки моның өчен бездә бөтен шартлар, бөтен мөмкинлекләр бар. *П. Н. Кормишова.*

Казан Шәһәр Советы депутаты.

ЯҢА УҢЫШЛАР ӨЧЕН

Без, бөек Ватаныбызның тимер юлчылар армиясе, 1939 нчы елны партиябезнең һәм хөкүмәтебезнең яңа ихтирамына, яңа мәхәббәтенә ия булдык. 3.000 нән артык тимер юлчы дәүләт заданияләрен уңышлы үтәве өчен ССР Союзы орденнары һәм медальләре белән бүләкләнде. Шул исәптән мин дә, тимер юлның яңа күтәрелеше өчен көрәштә күренекле эшем өчен Ленин ордены белән бүләкләндем. Бу ел мин хезмәт ияләре депутатларының район Советына депутат итеп сайландым.

1940 нчы елда тагын да яхшырак эшләү, Кривонос, Огнев, Папавин иптәшләр кебек атаклы машинистларның методын җентекләп үзләштерү, 32 ел буена машинист булып эшләү дәверемдә тупланган бай тәҗрибәмне яшьләргә өйрәтү, аларның да үзем кебек эшләүләренә ирешү, хезмәт ияләре депутатларының район Советы депутаты дигән бөек исемне намуслы хезмәт белән аклау—яңа, тагын да бәхетлерәк ел теләкләрем әнә шулар. *М. Г. Крылов.*

Юдино депосының орденлы машинисты.

1940 НЧЫ ЕЛ—ЯҢА ЖИҢҮЛӘР ЕЛЫ БУЛЫР

1939 нчы ел минем хәтеремдә озак еллар саклаңыр. Производствода яхшы эшләвем,—намуслы хезмәтем өчен СССР Верховный Советы Президиумы указы буенча „Аеруча хезмәт күрсәткән өчен“ медале белән бүләкләндем.

Энергокомбинат коллективы шәһәр Советына депутатлыкка минем кандидатурамны күрсәтте. Һәм 232 нче номерлы округның сайлаучылары мине Казан шәһәр Советына депутат итеп сайлап, миңа зур ышаныч белдерделәр.

1940 нчы елга кердек. Бу ел яңа җиңүләр елы булыр. Мин 1940 нчы ел башыннан ук тагын да яхшырак эшләү өчен үз алдыма конкрет бурычлар куям. Шәһәрне һәм аның хезмәт ияләрен электроэнергия белән тәэмин итүдә үз эшемне намус белән үтәячәкмен. Авариясез эшләүнең гүзәл үрнәкләрен бирермен. Производство өчен яңа такдимнәр хәзерлим. *И. В. Романов.*

Энергокомбинат мастеры.

Гариф Галиев

Еракtагы бер авылда

Тышта буран котыра. Халык әйтмешли, ат башы кадәр алтын бирсәләр дә юлга чыкмассың! Кәкре Атау бөтен авылы белән өйдә бүген.

Бу, үзе, республикабызның читендә, ерак почмакка урнашкан йөз илле хуҗалыклы гына бер авыл. Бу Кәкре Атау авылы.

Шушындый коточкыч буранлы көннәрдә җыелышып кич утырырга айрата яраталар биредә. Урамда кар коймаларны күмә, читән буйларына биек-биек сырындылар өеп китә, каралты түбәләрен туздыта. Ләкин яктылыклары тәрәзә аркылы бөтен урам буйлап төшкән утларны сүндерә алмый ул. Кайбер өйләрдә өстәлгә, кайберләрендә сәкегә куелган, ә кайберләрендә кучкар буена урнаштырылган менә шул лампалар тирәсендә кызлар кемнәргәдер җылы оек башлары бәйлиләр, сабын суы белән мамык перчаткалар басалар, ак шарфлар өчен йон җепләре каталар. Бу перчаткалар, бу шарфлар кемнәр өчен хәзерләнә,—моны белүе бик үк ансат эш түгел. Андый серне аны бер сорау белән генә әйтеп салмыйлар. Һәр хәлдә боларның ияләре арасында Көнбатыш Украина, Көнбатыш Белоруссия халкын азатлыкка чыгаруда катнашкан, ә хәзер запас линияләрдә тора торган егетләр дә, фин халкын азат итүче боецлар да бар. Шулай дип уйларга аның сәбәбе дә юк түгел. Чөнки мондый буранда кем генә килеп ишек шакымасын, өйдәгеләр, кинәт, ашыгып, урыннарыннан кузгалалар һәм:

— Ибраһим абзый түгелме икән?—дип ишек ачалар алар.

Ә Ибраһим абзый ул—бөтен Кәкре Атауга бер кеше. Ерак җирләр, текә таулар һәм киң диңгезләр кичеп килгән хатларны Кәкре Атаулар менә шушы Ибраһим абзыйлары аркылы алалар. Ерак Көнчыгыш краенда шәһәрләргә шәһәр булып килә торган яңа шәһәр—Комсомольский хәбәрләрен дә бирегә Ибраһим абзый китерә. Кәкре Атауның мондый ерак шәһәрләрдә, зур төзелешләрдә катнашучы егетләре күп аның. Шуның өчен Ибраһим абзыйның кайчан почта алырга китүе, аннан кайчан кайтуы биредә һәр кем өчен бик билгеле һәм аның шушындый күз ачмаслык бураннарда да кемгә дә булса хат белән—хәбәр белән килеп керүе бик мөмкин.

Хат көтүнең авыр, бер үк вакытта бик рәхәт тә икәнен, аны үзе кичергән кешеләр генә белә. Шундый көткән хатларны кайтарып биргән кеше ул сиңа якыннарыңның да якыны кебек тоела. Көтеп алынган Ибраһим абзый исә, ул бер вакытта да буш булмый. Аның җилкәсе аркылы аскан, аз гына каешлана башлаган брезент букчасында Донбасс шахталарында эшләүчеләрдән дә, Тагиль ягында эшләүчеләрдән дә һәм Комсомольский шәһәрен төзүчеләрдән С. Сабировлардан да хатлар була. Ә инде хатлар күп булмый икән, бу сумкада газеталар була. Ә газетада Хасан күле бәрелешләренә катнашып, геройлыгы өчен „Кызыл Йолдыз“ ордены белән бүләкләнгән күрше авылның Камиль Фәтхеттинев иптәш турында да күрше авыл егете Х. Мусин язган шигырь була. Кич утыручылар җыелышаларда менә шул шигырьне әйнәләр [1]. Һәм ул аларның үзләре белгән егет тарафыннан язылып, үзләренең район газетасында („Октябрь колхозчысы“) басылган булганлыктан бик кызыклы да булып чыга.

Шулай кич утырдык та, клубка чыгып киттек. Карлы-бозлы җил тынга каплана, атларга ирек бирми,—артка этә.

Ишек ачылуга әчтән курай тавышы ишетелә. Ашыга-ашыга өсбашларыбызны селеккәлибез дә, клубның аргы башына таба атлыйбыз. Баксаң, анда, патефонда башкырт курайчыларының „Буранбай“ көен тыңлыйлар. Сүзгә яптәш кенә бер агай:

— Менә,—ди,—тышта буран уйнагач, клубта „Буранбай“ны уйната башладык әле,—ди.

— Хәзер менә „Урал“ ны куябыз. Урал үзе ерак булса да көе менә биредә генә аның,—дип өсти аның белән рәттән утыручы икенчесе.

Патефон „Урал“ ны башлый. Бер төркем халык белән патефон уйнаган курай тавышы астында җай гына сөйләшеп утырабыз.

— Бу арада бәйрәм артыннан бәйрәм әле, иптәш.

— Ничек?—дип сорыйбыз без алардан.

— Егерме берендә иптәш Сталинга алтмыш яшь тулды. Мәҗлесләрдә аңа озын гомерләр теләдек. Бездә аның Москва шәһәренең Сталинский районы сайлаучыларының сайлау алды җыелышларында сөйләгән речe язылган пластинка бар. Ул көнне берничә тапкыр шул пластинканы уйнатып утырдык. Иптәш Сталинның тавышы бик матур бит аның, аннары бер дә ашыкмыйча сөйли икән ул. Сүзе дә бик ачык. Берсе артыннан берсен аңлап кына барасың. Егерме дүртендә сайлаулар булды. Ә сайлауны, без аны сәгать көндезге уникегә үк тамам иттек. Бездә Сәгыйров фамилияле бер нәсел бар. Алар егермеләп саналалар.

Шулар көндезге сәгать унбер булганда сайлауга барсы да килеп беткәннәр иде инде. Ул көн дә кунак-төшемсез үтмәде. Безнең авылдан чыккан ике поселкы бар бит, аларда торучылар сайлауга безгә килделәр. Берәве кода булса, икенче берсе кияү дигәндәй, аларны да хөрмәт итмичә булмый. Шулай итеп сайлау көне дә бәйрәмгә әверелде.

— Менә хәзер тагы яңа ел җитә. Аны да бәйрәм итәбез,—дип сүз башлый икенче бер агай.

Яңа ел турында сүз кузгалу белән без үткән 1939 нчы ел белән кызыксынабыз. Сөйләшә торгач, колхоз елының бик матур йомгаклары килеп чыга.

— Үтеп бара торган бу 1939 нчы елның сагынып сөйләрлек көннәре бик күп аның,—ди Бөтенсоюз Авыл Хуҗалыгы Күргәзмәсенә катнашучы Нәби иптәш Шәйдуллин.

Аның сүзен куәтләп китәләр:

— Бу бит енотлар караучы. Енот фермасы бар бит бездә. Нәби күргәзмәдән кайткач, төлке фермасы да оештырып җибәрдек. Нәбиебез күргәзмәдә төлкеләр күреп кайтты да авыз да ачтырмый бит, очраган беребезгә төлке турында, аның доходлылыгы турында сөйли. Каршы килмәдек, риза булдык һәм һәрберсен мең ярымнан дүрт баш нәсел төлкесе кайтарттык. Кара көмеш төсле төлкеләр. Әйәй әйбәтләр. Җәт күргәнсездер дә әле?

— Быел без автомашина да алдык.

Локомобилле дә булдык.

— Тегермән юк иде, аны сала башладык. Шунда ук тула машинасы да корабыз.

— Быел тагы менә бу бар, безнең сыерлар бу вакытка кадәр бөтенләе белән нәсел кнәгәсендә түгел иде, ә быел ферманың барлык сыерлары нәсел кнәгәсенә кертелде.

— Тимерчелек, столярный мастерскойлар ачтык. Бик күп эшләр эшләдек без быел, иптәш.

— Мастерской дигәннән шул ике мастерскойдан безгә быел 14 мең сум доход бирде түгелме?—дип сорау белән башкаларга карап ала Хәмидуллин.

— Әйе, ундүрт мең сум бирде шул, карап торсаң, юк кына нәрсә бит үзе, ә доходны китерә,—дип аның сүзен раслыйлар.—Мунчала ташып егерме мең сум доход алдык. Чәчкән икмәккә генә карап торсаң, ярамый бит ул. Икмәк өстенә шундый доходларың булса иркенгәрәк килә.

— Китерә белсәң доход килә инде ул,—дип куя башкаларны тыңлап кына утыручы берәү.

Сөйләшү озакка сузыла. Ләкин берәү дә сөйләшеп туймый. Чөнки колхоз елы берсеннән-берсе кызык, сөйләп туймаслык көннәрдән тора. Һәм Баяз абзый:

— Без үсәбез егетләр, сез менә колхоз оешкан елны гына алып карагыз, авылда тимер тырма да юк иде бит ул чакта, хәзер исә колхоз төзелешенә ун ел тулганда нинди генә машиналар юк бездә, уйлап карасаң, аптырыйсың, бигрәк надан яшәгәнбез без элек. Пример, менә 7—8 чакырымга сузылган авыл буендагы әлеге шушы Кара Күл, ул чакта да бар иде бит. Ә без шуннан җәй көне дә рәтләп файдалана алмый идек. Ә хәзер аның балыгын кыш көне дә тотабыз,—дип бик дөрес әйтә.

Утыра торгач байтак вакыт үткән, без кайтырга җыенабыз. Кемдер патефонга „Вдоль деревни“ пластинкасын куя.

Вдоль деревни от избы до избы,
Зашагали торопливые столбы.
Эх, загудели, заиграли провода
Мы токого не видали ни когда.

— Менә бусы шәп ичмасам, моны тыңлаганда бер генә нәрсә җитми, ул да булса, тагын да күңеллерәк булыр иде бу көйне уйнату,—ди Нәби.

— Анысы яңа елны каршылаган да булыр инде аның,—ди к... шәләр башкалар.

Тышта буран басылга... тынып калган. Тик берн... нан таң әтәчләре тавы... ишетелә.

Ок...
Кәкр...

25—28 декабрь.

1) укыйлар магнәсендә.

Чит илләрдә

ЕВРОПА СУГЫШЫ

ЛОНДОН, 30 декабрь. (ТАСС). Рейтер агентлыгы сугышның беренче дүрт ае эчендә Англия авиациясенең хәрәкәтләре турында түбәндәге йомгакларны бирә:

25 нче декабрьгә кадәр Англиянең яр буе оборонасындагы самолетлар 44 мең сәгат очып, 3.750 мең миль араны үткәннәр. Шулай итеп бу самолетлар һәр көн уртача җир шары әйләнәсеннән күбрәк араны үткән булалар. Англия самолетлары дошманның су асты көймәләрен 107 тапкыр күргәннәр һәм су асты көймәләренә 57 тапкыр һөҗүм иткәннәр. Моннан тыш Англия самолетлары судноларның 400 караванын саклап алып барганнар. Англия бомбардировщикларының берләшмәләре 27 тапкыр Германия өстендә күпләп очып йөргәннәр.

Англия бомбардировщикларының берләшмәләре сугышның беренче көннәрендә Германия өстендә 4.250 мең листовка ташлаганнар. Моннан тыш Англия самолетлары Германиянең төп промышленность үзәкләре өстендә, шул исәптән Берлин һәм Потсдам өстендә күренгәннәр.

Германия авиациясе шушы вакытка кадәр Англиягә киң күләмдә налетлар ясамаганлыктан, Англия истребительләре берләшмәләре, чикне саклаучы отрядларга һәм бомбардировщикларның берләшмәләренә караганда, кимрәк очканнар. Шулай да, Англия истребительләре Германия самолетларының аерым налетларын уңышлы рәвештә кире кайтарганнар.

Агентлыкның ахырдан күрсәтүенә караганда, Англия һәм Франциянең хәрби һава көчләренең бергәләп хәрәкәт итүләре турында сугыш хәрәкәтләре башланганга кадәр үк күп кенә чаралар үткәрелгән. Сугыш башлануга берничә көн калганда Франциягә бомбардировщикларның, шулай ук истребительләрнең берничә эскадрелиясе җибәрелгән булган. Англия самолетлары Франция авиациясе белән бергә хәрәкәт итеп, дошман ныгытмаларының күп кенә рәсемнәрен алганнар. Моннан тыш Англия истребительләре нәтиҗәле рәвештә Франциянең портларын саклаганнар. Бу—дошман тарафыннан комачаулык китерелмичә, Англиянең экспедиция армиясен Франциягә күчерүне тәгәлләргә мөмкинлек биргән.

ПАРИЖ, 30 декабрь. (ТАСС). Гавас агентлыгы кичә кич белән Парижда иглан ителгән түбәндәге белдерүне тапшыра: „Авиациянең хәрәкәтләре яңадан башланды. Безнең алдынгы частьләребезнең беркадәр активлыгы күренде. Вогез районында безнең күзәтүче отрядыбыз дошманның патруль отрядыннан берничә солдатны пленгә алды“.

Бүген иртә белән иглан ителгән белдерүдә болай диелә:

„Һава салкын булуга карамастан, Мозель белән Саар арасында патрульләрнеңхәрәкәтләре күренә. Кичә күрсәтелгәнчә, авиациянең көчәйгән хәрәкәте хәзергә, бәрелешләргә китермәде“.

Катокта. Художник Шамазов рәсме.

КАПИТАЛИСТИК ИЛЛӘРДӘ ЭШСЕЗЛӘРНЕҢ САНЫ 16,5 МИЛЛИОНГА ҖИТӘ

Германиянең „Виртшафт унд статистик“ журналының башлангыч маглүматларына караганда, 1939 нчы елда Европаның 19 илендә, Австралия союзында, Яңа Зелландиядә, Канадада һәм АКШ та эшсезләрнең гомуми саны 16,5 миллион кешегә җиткән.

Европа илләре арасында Англиядә эшсезләр башка илләрдәгегә караганда күбрәк. Октябрь ахрына Англиядә эшсезләрнең саны 1.431 мең кешегә җиткән. Сугыш башланыр алдыннан Франциядә эшсезләрнең саны 303 мең кеше иде. Сентябрь аенда мобилизациягә карамастан, Франциядә эшсезләрнең саны 825 мең кешегә кадәр артты.

Бельгиядә эшсезлек һәр вакыт үсә бара. Июль аенда илдә 173.732 эшсез бар иде, бу сан—1938 нче елның шул ук чоры белән чагыштырганда—14 процент күбрәк. Сугыш вактында Бельгиядә эшсезләрнең саны 227 мең кешегә кадәр артты. Голландиядә эшсезләр—240 мең, Швейцариядә—22 мең.

Швециядә бер ел эчендә эшсезләрнең саны 27 процент артты һәм 27.547 кешегә җитте.

Даниядә эшсезлек бигрәк тә зур. Августта илдә 56.000 эшсез бар иде. Англия—Франция блокадасы эшсезлекнең бик күп артуына сәбәп булды. Шушы кечкенә генә ил булган Даниядә хәзер 100 меңгә якын эшсез исәпләнә.

Рәсми маглүматларга караганда, АКШ та эшсезләр 11 миллион кешегә якын исәпләнә.

(ТАСС).

ЯҢА ЕЛ УҢАЕ БЕЛӘН ГИТЛЕРНЫҢ ПРИКАЗЫ

БЕРЛИН, 30 декабрь. (ТАСС). Германиянең информация бюросы яңа ел уңае белән Германиянең кораллы көчләренә Гитлер приказының эчтәлеген тапшыра: үзенең приказында Гитлер, 1939 нчы ел Германия армиясе өчен сынау елы булды, дип күрсәтә. Приказда болай диелә: Польшаны җиңү көнчыгышта Германиянең куркынычсызлыгын ныгытты һәм Версаль договорының гаделсезлеген бетерде. Приказда әйтелә: „Герман халкының язмышы бәйләнгән иң авыр көрәш—әле алда“. Ахырдан Гитлер Германиянең җиңәчәгенә ышанганлыгын белдерә.

Һиндстанда восстаниечеләр белән Англиянең чик буе частьләре арасында сугыш

КАБУЛ, 30 декабрь. (ТАСС). Дәһлидән (Һиндстан) хәбәр итүләренә караганда, шушы көннәрдә Вазиристан (Һиндстанның төньяк-көнбатыш чигендәге провинция) восстаниече кабиләләре белән Англиянең чик буе частьләре арасында Банну районында сугыш булып, 12 сәгат дәвам иткән. Һәр ике яктан үлүчеләр һәм яралалнучылар бар.

АНГЛИЯДӘ СУГЫШКА КАРШЫ ХӘРӘКӘТ

ЛОНДОН, 30 декабрь. (ТАСС). „Дейли уоркер“ газетасы, сугышка каршы резолюция кабул иткән оешмаларның исемлеген басып чыгаруда дәвам итә. Алар арасында—Ньюингтондагы (Лондонның төньяк өлеше) төзү эшчеләре союзы, Төньяк Стирлингширдәге (Шотландия) лейбористлар оешмасы һәм Уотфорддагы (Гердфорд графствосы) яшьләрнең кооператив оешмасы бар.

„Яңа ел бүләкләре“

…че кварталлары өстендә. …сме (ТАСС фото-клишесе).

ЯҢА ЕЛ ТАҢЫНДА

Мин урамга чыктым,
Эх, кыш матур,
Ак кар күмгән йортлар түбәсен,
Йөгерә-йөгерә җирдә гөрләп йөри
Чүпләнгәләп күксел күгәрчен.
Чапай булып уйный урамнарда
Күз нурларым нәни балалар,
Йөктә килгән яшел печәннәрне
Шаярышып йолкып калалар.
Кыш матур шул,
Әле менә
Уйлап кайтам шул кыш хакында,
Бер дустым бар минем,
Кичә шулай
Борнын өшетеп кайткан салкынга.
Борнын тотып кышка ачулана,
Карыйм да мин аңа, елмаям;
Кичә җәй үткәнгә кайгыра идем,
Бүген кыш үткәнгә моңаям.
Тау буенда минем нәни дуслар
Чана шуа, кайсы бүрексез;
Чаналарда шуган балалар күк
Гомер үтә һаман өзлексез.
Үтсә үтәр әйдә безнең гомер,
Ләкин үтә көннәр бәхетле,
Җимердек без мең ел газаплаган
Сарайдагы алтын тәхетне.
Без корабыз җирдә коммунизм,
Безнең турыда килер буыннар,—
Яңа елны каршы алган чакта
Безне мактап җырлап йөрерләр.
Экран битләрендә яңрап торыр,
Походларда йөргән чагыбыз
Онтылмас җыр булып гасырларда
Барыр безнең җиңү даныбыз.
Күтәрик без, дуслар, бокалларны
Үткән уңыш, килер ел өчен,
Даһиебыз Сталин гомере өчен
Эчик балның куе, татлысын!
Сталин белән кышның буранын да,
Салкынын да сизми калабыз,
Ул күтәргән алсу байракларны—
Без күтәреп алга барабыз.
Эх!
Сугыш бара ерак тайгада,
фин халкының хакын даулыйбыз,
Туганыбыз, якын финнәрне без
Богау белән калдыра алмыйбыз.
Финляндия! Тиздән яз булыр,
Туплар очмас синең кырыңнан;
Килер елны бергә шатланырбыз,
Бәй чишелер синең кулыңнан.

Нур Баян

Декабрь, 1939 ел.

1940

(Яңа ел җырлары)

„Үтәсең гомер, ай үтәсең...“
(Иске җыр)

Үтә гомер, үтә гомер,
Айларны ел итә ул,
Айларны ел итә-итә
Безне алга илтә ул.

Каршылыйбыз бу елны да
Былтыргыдан уздырып,
Эпосларда җырланырлык
Батырлыклар тудырып.

„Үтә гомер...“ дип моңаю
Безнең башка сыймый ул:
Үтә бит, дип утырганда
Туктап тора мени ул!

Елларны стахановларча
Яшәп булган сәбәпле,
Уза да бит тора бу, дип
Тиргәмибез сәгатне.

Алга, дуслар, давылларны,
Дулкыннарны ярдырып,
Чоры узган чараларны
Истәлеккә калдырып!

Үтә, үтә алга илтә
Безне бөек бишьеллар:
Төнәгеннән—бүген гүзәл,
Былтыргыдан—быеллар!

Алга, дуслар, давылларны,
Дулкыннарны ярдырып,
Эпосларда җырланырлык
Үлмәс эшләр калдырып!

Янра син меңнәрчә телдә,
Магнәсе бер төрле җыр:
Бәхтебез остасы Сталин,
Үзең дә исән-сау тор!

Батырлык илһамчысы син,
Бөеклек үрнәге син,
Син безнең йөрәк җырыбыз,
җырларның йөрәге син!

Хәсән Туфан.

Рәхим ит, гүзәл яңа ел!

Ашкынып килә яңа ел
Яңа илне күрергә,
Яңа илнең, яңа җирнең
Тарихына керергә.

Һәм безгә рәхмәт әйтер ул
Яхшылап каршы алсак,
Һәр көне, һәр сәгатендә
Өзлексез җиңеп барсак.

Әйдә, рәхим ит Яңа ел,
Түргә уз, кыю атла,
Сталин бишьеллыклары
Көтәләр сине сафка!

Һәр көнең Совет илендә
Якты һәм ямле үтәр,
Бөек азатлык Ватаны
Тагын да яхшы үсәр.

М. Садри.

1939 ел.

Укучы балаларга күңелле ял

Кышкы каникуллар башланды. Барлык мәктәпләрдә, балалар учреждениеләрендә балалар өчен яңа ел елкалары оештырыла. Ирек майданына 6 метрлы зур елка һәм шундый ук зур күләмдә Кыш бабай куелды. Монда төрле уенчыклар һәм азык әйберләре сату лареклары эшләячәк.

Пионерлар һәм мәктәп балалары йортында шәһәр балалары өчен 12 көн буена елка кичәләре үткәреләчәк. Бу кичәләр аркылы барлыгы 7 мең балага хезмәт күрсәтеләчәк.

Яш тамашачылар театрында көн саен 2 спектакль биреләчәк.

Татарстанның курчак театры күп кенә мәктәпләрдә һәм клубларда күчмә спектакльләр бирә.

Шәһәрнең эшче клубларында елкалар оештырыла. Менжинский исемендәге клубның спорт залында зур елка бизәлде. Монда 1 нче гыйнвардан 3 нә кадәр елка кичәләре үткәрелә. Балалар өчен махсус кино-сеанслар биреләчәк. Клуб дирекциясе елка кичәләрендә өләшү өчен 1.300 балага күп төрле бүләкләр хәзерләде.

„Динамо“ спорт җәмгыяте физкультураның кышкы төрләре буенча балаларның ярышларын үткәрә. Массовый уеннар оештырыла. Шулай ук шәһәр тирәсенә чаңгыларда походлар үткәреләчәк. 12 нче гыйнварда клубның яш үсмерләрдән торган драмтүгәрәк „Школьный учитель“ ...девилен сәхнәгә куя.

Кызыл Армия йорты 1 нче гыйнвардан 12 сенә кадәр балалар белән гөрләп торачак. Балалар өчен концертлар, спектакльләр биреләчәк. Елка янында кичәләр үткәреләчәк. Шулай ук кызыл армия частьләрендә дә елка кичәләре булачак.

Шәһәр музейләренә һәм зверинецка экскурсияләр оештырыла.

Укытучылар йорты 10 нчы класс укучылары өчен бал-маскарад үткәрә. Иң яхшы биючегә, җырчыга һәм сөйләүчегә конкурс иглан ителә. Каникул вактында балаларның ату спорты ярышларын үткәрү күздә тотыла.

Яш шахматчылар, СССР шахмат мастерлыгына кандидат иптәш Нәҗметдинов белән очрашачаклар. Каникул вактында балалар Союз орденнары һәм медальләре белән бүләкләнгән алдынгы укытучылар белән очрашачаклар. Үзешчәнлек сәнгате түгәрәкләре каникул көннәре өчен махсус чыгышлар хәзерлиләр.

Балаларның Туризм һәм Экскурсияләр Станциясе кышкы каникул вактында укучы балалар өчен Москва һәм Горький шәһәрләренә экскурсияләр оештыра. Туристларның 3 көнлек походларында 2.000 нән артык укучы катнашачак. Шулай ук Юдинога, Васильевога, Зеленый Долга, Бөреле совхозына, Ленино авылына һәм Зөягә экскурсияләр оештырылачак. 6 нчы гыйнварда яш натуралистларның Казан Авыл Хуҗалыгы институтының фәнни работниклары белән очрашулары булачак.

Тренировкалар үтү өчен 2 чаңгы базасы төзелде.

Совет-сәүдә работниклары клубы 1 нче гыйнвардан 6 нчы гыйнварга кадәр елка үткәрә. Елкада 600 балага хезмәт күрсәтеләчәк.

„Спартак“ комбинаты клубында да елка янында балалар иртәлекләре үткәрелә. Шулай ук шәһәр елкасына да билетлар сатып алынды.

ЗУР ТЕАТРДА „МАСКАРАД“ ПРЕМЬЕРАСЫ

Гыйнварның беренче числоларында Зур Драма театрында чираттагы постановка булып Лермонтовның „Маскарад“ пьесасы барачак. Премьераны сәхнәгә театрның художество житәкчесе һәм баш режиссеры Яков Абрамович Варшавский куя.

Спектакльдә Орбенин ролен Татарстанның халык артисты Ардаров, Нина ролен Капустина һәм Лесная, князь ролен Казанский, Шпрех ролен—Татарстанның халык артисты Якушенко һәм Шейнин иптәшләр башкаралар. Спектакльләр художник Бельский оформлениясендә барачак. Шигырьләр С. Шервинский эшләнешендә алып барылачак.

ТАТАР ДӘҮЛӘТ АКАДЕМИЯ ТЕАТРЫНДА ЯҢА СПЕКТАКЛЬЛӘР

Галиаскәр Камал исемендәге Татар Дәүләт Академия театры гыйнвар аенда күрсәтү өчен ике премьера — орденлы драматург Таҗи Гыйззәтнең „Кыю кызлар“ һәм Н. Исәнбәтнең „Болак арты республикасы“ әсәрләрен хәзерли.

Ярты еллык репертуар планына Шекспирның „Ромео һәм Джульета“ трагедиясе, Аблиевның „Лейтенант“ пьесасы һәм Фәтхи Бурнашның „Ялгыз Ярулла“ дигән пьесалары кертелде. Драматург Исәнбәт фольклор буенча эшләнгән Хуҗа Насретдин пьесасын тәмамлап килә.

Драматург Риза Ишмуратов В. И. Лениннең яшьлек елларын күрсәткән „Юлбашчының яшьлеге“ дигән пьеса өстендә эшли. Бу пьеса Владимир Ильичнең Казанда яшәгән чорын чагылдырачак.

Җаваплы редактор
Һ. АБДРАХМАНОВ.
Ответ. редактор Х. АБДРАХМАНОВ.

БҮГЕН ТЕАТРЛАРДА ҺӘМ КИНОЛАРДА

Зур Драма театры—көндез һәм кич „Бакчалар чәчәк ата“. Талоннар: көндез 14, кич 66.

Культура сарае (Киров районы)—Павел Греков. Талоннар: 37 һәм 38.

Дәүләт циркы—һәр көн бәйрәм программасы буенча көндез 11 сәгаттә һәм 2 сәгат 30 минутта, шулай ук кич 8 дә зур цирк уеннары.

Фән работниклары йорты—яңа ел елкасы.

„Электро“—Характерлы кыз. „Унион“—Дуслар янадан очрашалар. Һәр көн көндез 10 сәгаттә балалар өчен сеанс бирелә. „Кызыл Йолдыз“—көндез Алтын ачкыч һәм кич Бөек гражданин (2 нче сериясе). „Чаткы“—Куәтле ташкын. „Пионер“—көндез һәм кич Һава почтасы. Һәр көн көндез 1 сәгаттә мәктәпкә кадәр яштәге балалар өчен сеанс—Вагя капитан. Фойедә елка. „Колхозник“—Унөч. „Рот-фронт“—Сорочинская ярмарка. Культура сарае—Сентябрьдәге төн.

ТУЙ КҮҢЕЛЛЕ БУЛСЫН

(Хикәя)

Көне буе өстәл артында утырып эшләү ялыктырган, башны авырттырган икән, мин аны менә шушы коры һавада гына сизәм. Бу һаваны озаграк сулыйсы килә. Мин җәяү кайтам. Аяк астында кар шыгырдый, бәрәңге оны кебек уылып кала. Кышкы салкын бөтен гәүдәне җиңеләйткән кебек итә, аяклар кызуырак атлый башлыйлар.

Бераздан мин, яш егетләр кебек, битләремне кызартып, алсуланып өйгә кайтып керәм. Ишек ябарга да өлгермим, Маратик килеп җитә:

— Әти, әти, әбисәдән тагы хат килде.

Ул мин чишенгән вакытта, ашыга-ашыга әбисенең хатта язган сүзләрен сөйләп чыга. Маратик сөйләгәч, хатны укымаска да мөмкин иде. Ләкин мин әнинең хатын да, улымның кызыксынуын да игтибарсыз калдырырга теләмим. Менә бит, ул кечкенә Маратик үз сүзенең дөреслеген раслауны көтеп тора, ә аның өчен хатны укымый булмый. Мин диванга килеп утырам. Минем тезгә Маратик атлана һәм мин һәрбер хат саен кабатлана торган „янәдә“ сүзләре белән саналган авыл халкы исемлеген һәм алардан җибәрелгән сәламне укып чыгам. Аннан соң йорт-җирнең иминлеген, мүкләк кәҗәнең быел да ике бәрән китерүен, кара сарыкның әле һаман бәрәнләми торуын, шуңа күрә көн-төн саклауларын беләм. Бер вакыт „дәхи монысы да маглүм булсын“ дигән юллар белән авыл хәбәрләренә кереп китәм.

Минем йөрәк ярсый башлый. Авылдагы искиткеч үзгәрешләрне үз күзем белән күрәсем килә, әле мин киткәндә агач атка атланып чабышкан малайларның, чүплек башында төрле матур ташлар белән уйнап утырган нәни кызларның укытучы, агроном, тракторист, мәктәп директоры, РИК председателе, райком инструкторы булып күтәрелүләре мине шатландыра. Минем алар белән сөйләшәсем, аларга карап хозурланасым, туганнарча ягымлы караш белән иркәлисем килә.

Тик мин һаман кайта алмыйм. Дөресен әйткәндә, 6 сәгатлек юл өчен кайтып килүемә 6 тәүлек әрәм итәсем килми!...

Әни моны бик яхшы белә һәм бу юлы да үпкәләп яза:

— Кайт дип тә язмыйм инде. Каз өмәләренә дә кайтмадың. Син һаман шул Казан—Бөгелмә тимер юлы салынып бетүне көтәсең. Бер атна вактыңны кызганасың. Тагы ике ел бит әле ул юлыңа синең! Менә Сибгатулла белән Мөршидәнең туена хәзерләнәбез. Яңа елны каршы алганда туйлары була. Кайтсаң скрипкаңны уйнар идең.

Әнинең төрле юллар белән кайтарасы килә. Бер генә көнгә, бер генә кичкә, Сибгатулла туена гына!..

Әнинең хатын өстәлгә куям һәм улымның башыннан сыйпый башлыйм. Тирән уйга чумам. Яшьләр үсәләр. Әнә Сибгатулла укытучы белән комбайнерка Мөршидә бәхетле, шат тормышларын берләштерәләр. Аларның яңа тормыш бәйрәменә бөтен колхоз катнаша, ә мин—Сибгатулланың агасы—ун сүзле тәбрик телеграммасы белән чикләнерменме?!

Нишлим соң?

Энемнең туена катнашу өчен тәүлекләр буе кирегә китеп Рузаевка аша кайтырга чыгыйммы? Бер кич туй ясау өчен 6 көнне юлда уздырыйммы? Ә хезмәтем?...

Минем йөрәгем ешрак тибә башлый. Казан—Бөгелмә юлын бер көндә салып бетерәсем килә. Юл төзүчеләрне ашыктырасым, өргеч белән көч өрдерәсем килә башлый...

— Әйе, әни, мин ул юлның беренче пассажиры булып кайтырмын! Син ындыр артыннан әрәмәлек аша гына чыгып вокзалга килерсең, улыңны һәм аның кара күзле, күп сөйләүчән улын каршы алырсың! Мин куәтле паровозлар ярдәме белән 5—6 сәгаттә кайтып җитәрмен, ун елга бер түгел, еш-еш кына ял көннәремне уздырырга кайтырмын!.. Ә хәзергә...

Маратикны диванга утыртып, мин бүлмә буйлап йөри башладым. Үземә урын таба алмыйм. Йөрәктән әллә нинди әче хисләр күтәрелә, күкрәктән дәрт таша, беләккә көч тула. Юл төзү эшенә үзем тотынасым килә башлый. Меңләгән аналарны балалары белән күрештерер идем кебек. Меңләгән балаларга шәһәргә килеп уку эшен җайлап идем төсле, колхозчыларның икмәкләренә, симез казларына Казанга килү мөмкинлеге бирер идем шикелле...

Әйе, чынлап та шулай эшләргә кирәк, чынлап та юл төзү эшенә үземә тотынырга кирәк...

Мин тиз генә өстәл артына килеп утырам. Яшел абажур астыннан бөркелгән ут яктысында хат яза башлыйм...

Әнигә сәлам языла, күрше-күләннәргә җавап рәвешендә, әни хатындагыча озын исемлек сузыла. Аннан соң мин төп мәсьәләгә күчәм һәм түбәндәгечә язам:

Сибгатулла энем, Мөршидә туганкай! Сезне бәхетле, яңа тормыш, шатлыклы яңа ел белән тәбрик итәм. Туегызга кайта алмам инде, каз бәлешләрегезгә авыз тидерә алмыйм. Әммә бәби туегызга кайтачакмын!.. Моның өчен барыбыз да үзен бер җаваплы эшкә мобилизовать итәргә тиеш! Казан—Бөгелмә тимер юлы төзелешенә бөтенебез кулдан килгән ярдәмне күрсәтик, шул эшкә үзебезне җигик! Бу—минем сезнең бәхетле яшәвегезне теләп язган котлау сүзләрем булсын! Киләсе елларның яңа елларын Казанда да, Уфада да уздыра алырбыз!.. Алай гына да түгел, без бергәләшеп театрларга йөрербез. Башкырт операсын тыңлап чыккач вагонда тәэсирләрне бүлешеп кайтырбыз, опера тыңлап, спектакль карап чыкканнан соң, иртәгәге эшкә кайтасыгыз килсә, мин сезне озатырга вокзалга төшәрмен!.. Шундый яхшы булыр ул юл...

Шулай, минем туганнарым, яңа елда, сезнең туегыз вактында мин яңа юл өчен, яңа бәхетләр өчен бокал күтәрәм!..

Туй күңелле булсын, Сибгат, юллар тиз салынсын!..

Газый Кашшаф.

УПОЛН. ГЛАВЛИТА ТАССР. № А —2593. ТИПОГРАФИЯ ИМЕНИ АЛЕКСАНДРОВА ДОМ ПЕЧАТИ. 1940 ГОД. ЗАКАЗ № 4899.